КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 21 март г.Казань № 310

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре бүлекләрен урнаштыруга һәм тулыландыруга карата бердәм таләпләрне раслау турында» 2013 ел, 4 апрель, 225 нче карары белән расланган үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре бүлекләрен урнаштыруга һәм тулыландыруга карата бердәм таләпләргә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре бүлекләрен урнаштыруга һәм тулыландыруга карата бердәм таләпләрне раслау турында» 2013 ел, 4 апрель, 225 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 11 ноябрь, 844 нче, 2019 ел, 09 сентябрь, 811 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре бүлекләрен урнаштыруга һәм тулыландыруга карата бердәм таләпләргә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

2.8 пунктның икенче абзацында «һәм урта, югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф оешмалары» сүзләрен «, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

2.11 пунктта «мәгълүмат текст һәм график төрләрдә урнаштырылырга мөмкин» сүзләрен «мәгълүмат квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 15 енә кадәр урнаштырыла» сүзләренә алмаштырырга;

2.13 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты указлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе указлары» сүзләренә алмаштырырга;

2.15 пунктының беренче абзацында «(законнарны аңлату буенча методик рекомендацияләр, хатлар, законнар таләпләрен гамәлгә ашыру буенча рекомендацияләр булган ведомствоара киңәшмәләр беркетмәләреннән өземтәләр)» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин